| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 февраль № 82

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартын раслау турында» 2016 ел, 3 май, 276 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартын раслау турында» 2016 ел, 3 май, 276 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартына(алга таба – Стандарт) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Комиссия үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 22 октябрь, б-1710 нчы боерыгы нигезендә төзелгән Татарстан Республикасында табыш күләме кимүне комплекслы анализлау үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – Ведомствоара эшче төркем), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 апрель, б-687 нче боерыгы нигезендә оештырылган Татарстан Республикасы консолидацияләнгән бюджетының үз керемнәрен үстерү буенча ведомствора комиссия (алга таба – Ведомствоара комиссия), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 15 июль, б-1493 нче боерыгы нигезендә оештырылган Татарстан Республикасы консолидацияләнгән бюджетына салымнар буенча бурычны киметү чараларын тормышка ашыру буенча ведомствора комиссия (штаб) (алга таба – Ведомствоара штаб) белән үзара бәйләнештә башкара һәм үз эшчәнлегендә аларның карарлары һәм тәгъдимнәренә таянып эш итә.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Комиссия түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

Оешмаларның Татарстан Республикасы консолидацияләнгән бюджетына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары барлыкка килү сәбәпләрен ай саен карап тикшерү һәм Оешмалар нигезләмә нигезендәге формалар буенча бирә торган мәгълүмат нигезендә аларны түләү буенча тәкъдимнәр эшләү;

Оешмалар нигезләмә нигезендәге формалар буенча бирә торган мәгълүмат нигезендә Оешмаларның финанс тотрыклылыгы кимү сәбәпләрен квартал саен карап тикшерү (чиста активлар күләмен устав капиталы күләме белән, кредит бурычы үсешен, төп чараларның кыйммәте кимү һәм заемнар һәм кредитлар суммасы артуны узган елның шул ук чоры белән чагыштыру);

квартал саен Ведомствоара эшче төркем каравына Оешмалар эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрү һәм беркетелгән икътисадый эшчәнлек төрләре буенча уртача россия буенча булган күләмнән түбән булмаган табыш дәрәҗәсенә җитү максатларында Оешмалар белән идарә итү системасын камилләштерү турында тәкъдимнәр кертү;

квартал саен Оешмалар табышын (зыянын) формалаштыруга, шулай ук узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда агымдагы чорда табышка салым керемнәре кимүгә тәэсир итә торган факторларны анализлау һәм гомумиләштерелгән мәгълүматны, күрсәтелгән анализ нәтиҗәләрен теркәп, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрә;

ел саен IV кварталда акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган һәм (яки) аларга карата махсус хокукны («алтын акцияләр») файдалану турында карар кабул ителгән акционерлык җәмгыятьләренең идарә органнарында дәүләт вәкилләре өчен директив формалаштыру өчен планлаштырыла торган елга табышның фаразланган мәгънәләрен карап тикшерү.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Эш йомгаклары буенча комиссия:

ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 көненә кадәр Ведомствоара штабка Татарстан Республикасы консолидацияләнгән бюджетына бурычлары булган Оешмалар белән үткәрелә торган эш барышы турында мәгълүмат җибәрә;

квартал саен Ведомствоара эшче төркемгә һәм Ведомствоара комиссиягә Оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, аларга булышлык күрсәтүнең күздә тотылган чаралары белән аналитик мәгълүмат җибәрә;

финанс-икътисадый тотрыклылыкны күтәрү турында, яңа сату базарларын эзләү хакында, Оешманың федераль һәм бүтән ярдәм күрсәтү программаларында катнашуы турында, барлыкка килгән хәлдән чыгуның бүтән юлларын эзләү хакында тәкъдимнәр формалаштыра;

Оешмага карата бурычларын түләргә хәле җитмәү (банкротлык) процедураларны алып баруны булдырмау максатында салымнар һәм җыемнар буенча булган бурычны каплау турында (Оешманың дебитор бурычы булганда – Россия Федерациясе Салым кодексының 8 бүлеге нигезендә салымнар һәм җыемнар буенча бурычны каплау турында, Россия Федерациясе Салым кодексының 9 бүлеге нигезендә салым түләү вакытларын үзгәртү буенча чаралар үткәрү хакында), ачык банкротлык процедурасы булганда – «Бурычларын түләргә хәле җитмәү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бурычлары өчен затлар тарафыннан каплау мөмкинлеге хакында тәкъдимнәр формалаштыра;

Комиссия утырышында кабул ителгән карарлар үтәлешен тикшерүдә тота һәм тәкъдимнәрне башкара.»;

4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Комиссия утырышында:

төп финанс күрсәткечләре начараю, шул исәптән беррәттән ике кварталдан артык табышка салым кимү, финанс нәтиҗәләре кимүне рөхсәт иткән Оешмалар эшчәнлекләре йомгаклары, дебитор бурычы структурасы (Министрлыкның баланс комиссиясе утырышларына Оешманың төп дебиторларын чакыру мөмкинлеге белән), барлык дәрәҗәдәге бюджетларга бурычны бүлеп биреп, Оешманың кредит бурычы структурасы, шулай ук хезмәт өчен түләү буенча агымдагы бурыч Оешмалар эшчәнлекләре йомгаклары карап тикшерелә һәм анализлана;

чакыру буенча (тавыш бирү хокуксыз) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкилләре, акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре һәм иптәшлекләренең идарә һәм контроль органнарында һәм (яки) аларга карата махсус хокукны («алтын акцияләр») файдалану турында карар кабул ителгән акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләре, Оешмалар вәкилләре, шулай ук кирәкле квалификацияләре һәм карар кабул итү өчен кирәкле махсус белемнәре булган белгечләр (экспертлар)катнаша ала.»;

4.8 – 4.10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Комиссия утырышларында карап тикшерү өчен Оешмаларны билгеләү максатында:

ай саен, хисап чорыннан соң килә торган икенче айның 27 көненә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Министрлыкка финанс нәтиҗәләре кимегән оешмалар исемлеген җибәрә;

квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Министрлыкка табышка түләнгән салым суммасы кимү билгеләнгән оешмалар исемлеген җибәрә;

ай саен Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Министрлыкка салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары һәм финанс тотрыклыгы начараю билгеләре булган оешмалар исемлеген җибәрү тәкъдим итәлә.

4.9. Комиссия утырышларында карап тикшерү өчен Оешмалар исемлеген формалаштыру максатында аның секретаре:

4.8 пунктта күрсәтелгән Оешмалар исемлеге белән эш итә;

Оешмаларга кирәкле, шул исәптән финанс, мәгълүматы бирү турында, кушымтага ярашлы рәвештә формалар буенча тармак үзенчәлеге нигезендә соратуларны таратуга әзерли;

карап тикшерелә торган Оешмаларның финанс хәлен объектив бәяләү максатында билгеләнгән тәртиптә ачык файдаланудагы барлык мөмкин булган мәгълүмат чыганакларын, шул исәптән тәэмин итә торган оешмаларның, контроль-күзәтчелек органнарының рәсми сайтларын куллана (газ, электр энергиясе, су өчен түләүдә җыелган бурычлары, эш хакын түләү буенча вакыты чыккан бурычлары, бүтән бурычлары булуны, шулай ук ачык башкарма производстволар булуны).

4.10. Баланс комиссияләрендә карап тикшерелә торган Оешмалар эшчәнлеген финанс-хуҗалык анализы Министрлыкның махсус белемле, тәҗрибәле, квалификацияле, аудитор эшчәнлеге (үзәкләштерелгән аудит) турында федераль закон таләпләренә туры килүче хезмәткәрләре яисә эксперт оешмасы (эксперт) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.11 пункт өстәргә:

«4.11. Комиссия утырышына чакыру һәм аның утырышында карап тикшерү өчен документлар пакеты, эксперт бәяләмәләрен дә кертеп, конфиденциальлек шартларын саклап, утырыш көненә кадәр биш эш көне алдан Комиссия әгъзаларына җибәрелә.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Комиссия хокуклары һәм бурычлары

5.1. Комиссия үзенә йөкләнгән функцияләр һәм бурычларны башкару өчен үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, Оешмалардан кирәкле, шул исәптән әлеге Стандартка кушымтада китерелгән мәгълүматны соратып алырга;

баланс комиссияләре утырышлары эшендә катнашуга фәнни хезмәткәрләрне, устав капиталларында Татарстан Республикасы өлеше булган Оешмаларның ревизия комиссияләре әгъзаларын, Министрлык белгечләрен, Оешмалар хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

тармак үзенчәлекләре һәм эшләү үзенчәлекләре нигезендә финанс-хуҗалык эшчәнлеге анализына һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләренә үз өстәмә таләпләрен эшләргә;

Оешма эшчәнлеге турында Оешмалар җитәкчеләрен тыңларга.

5.2. Комиссия үзенә йөкләнгән функцияләрне һәм бурычларны үтәү өчен үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләргә бурычлы:

Оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлегенә анализ үткәрергә, шул исәптән әлеге

Стандартка кушымта нигезендә формалар буенча бирелә торган мәгълүматлар нигезендә;

Комиссия утырышында карап тикшерелгән проблемалы мәсьәләләрне хәл итүдә Оешмага ярдәм күрсәтергә;

Оешманың финанс-икътисадый хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән тәкъдимнәрне мәнфәгатьле яклар (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре администрацияләренең тармак хезмәтләре җитәкчеләре, Оешмалар) игътибарына җиткерергә.

5.3. Оешманың финанслар белән идарә итү органнары яки финанс хезмәтләре компетенциясе җитәрлек булмаганлык билгеле булганда Комиссия аларның вәкилләренә квалификация күтәрү курсларын үтүне тәкъдим итә ала.

5.4. Комиссия әгъзалары Комиссия эшчәнлеге белән бәйле мәсьәләләрдә конфиденциальлекне сакларга тиеш.»;

Стандартка кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

2. Татарстан Республикасы министрлыкларына 30 көн эчендә министрлыклар каршында төзелгән баланс комиссияләре турында нигезләмәләрне әлеге карарга яраштырырга.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эре, икътисадый һәм социаль әһәмияткә ия булган предприятиеләрнең һәм оешмаларның икътисадый тотрыклылыгын арттыру һәм бөлгенлеккә төшүенә юл куймау буенча ведомствоара совет оештыру турында» 2011 ел, 30 ноябрь , 977 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эре, икътисадый һәм социаль әһәмияткә ия булган предприятиеләрнең һәм оешмаларның икътисадый тотрыклылыгын арттыру һәм бөлгенлеккә төшүенә юл куймау буенча ведомствоара совет оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 ноябрь , 977 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 7 март, 151 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 21 июнь, 528 нче карарының 2 пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\82.docx